**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАР № 22**

III чакырылыш XXVII утырышы Урыссу ш.т.б. «26» август 2019 ел

**Төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга бирү тәртибе турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга бирү тәртибе турында Нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» (“Ютазинская новь”) район газетасында бастырып чыгарырга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://jutaza.tatarstan.ru. адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

*Ютазы муниципаль районы Башлыгы –*

*Ютазы район Советы Рәисе* *Р.М. Нуриев*

Кушымта

Ютазы муниципаль

район Советы карарына

“___” ________ 2019 ел №

**Төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга бирү тәртибе турында Нигезләмә**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарга Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясында билгеләнгән аерым учреждениеләрдә, индивидуаль торак төзелеше яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен түләүсез файдалануга бирү тәртибен җайга сала.

1.2. Җир кишәрлекләре бирү Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Әлеге карарның максаты - авыл территорияләрен үстерү, Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы территориясендә эшләү өчен кирәкле категория белгечләрне җәлеп итү.

1.4. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре һәм дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

1.5. Җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга бирү һәм бушлай файдалану килешүләре төзү өчен формалаштыруны Ютазы муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасы гамәлгә ашыра.

1.6. Әлеге Нигезләмә 2016 елның 7 маендагы «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 32-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законы үз көченә кергәннән соң төп эш урынында эшли башлаган затларга кагыла.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга бушлай файдалануга җир кишәрлекләре бирү шартлары

2.1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре һәм аларга дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре, бер үк вакытта әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән шартлар булганда, гражданнарга индивидуаль торак төзелеше яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бер тапкыр түләүсез файдалануга бирелә.

2.2. Җир кишәрлекләре гариза бирү датасына бер үк вакытта түбәндәге шартларга җавап бирүче затларга бирелә:

1. Алар төп эш урыны буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче шәһәр яки авыл җирлекләрендәге оешмаларның түбәндәге төркемнәренең берсендә эшлиләр:

1) медицина оешмаларында түбәндәге белгечлекләр буенча: «дәвалау эше», «акушерлык эше», «шәфкать туташы эше"»;

2) мәгариф оешмаларында түбәндәге белгечлекләр буенча: «педагогик белем бирү», «мәктәпкәчә белем бирү», «башлангыч сыйныфларда белем бирү», «өстәмә белем бирү педагогы"»;

3) авыл хуҗалыгы оешмаларында «агрономия», «ветеринария», «зоотехния», «агроинженерия», «авыл хуҗалыгын механикалаштыру» белгечлекләре буенча.

2. Даими яшәү урыннары буенча гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә теркәлгәннәр.

3. Төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарга түләүсез файдалануга җир кишәрлекләре бирү тәртибе

3.1. Ютазы муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында төп эш урыннары буенча эшләүче гражданнарга бушлай файдалануга бирү өчен җир кишәрлекләре реестрын (алга таба - җир кишәрлекләре реестры) алып бара. Конкрет җир кишәрлеген формалаштыру эшләрен башкарганнан соң,

аның турында мәгълүмат җир кишәрлекләре реестрына кертелә (1 нче кушымта). Әлеге Реестр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана, «Ютазы таңы» (“Ютазинская новь”) район газетасында басыла һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

3.2. Бушлай файдалануга җир кишәрлеге бирү белән кызыксынучы гражданнар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына Россия Федерациясе Җир кодексы белән билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать итәләр.

3.3. Алар мөнәсәбәтендә җир кишәрлекләре бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән гражданнар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына бушлай файдалануга җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итәләр.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) гариза бирүче паспортының барлык битләренең күчермәләре (чагыштыру өчен оригинал );

2) эш урыны буенча расланган эшкә кабул итү турында боерыкның күчермәсе һәм хезмәт кенәгәсеннән өземтә.

3.4. Документлар белән бергә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гариза, карау өчен Ютазы муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләре палатасына җибәрелә һәм төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының эшләүче гражданнарның файдалануга бушлай җир кишәрлекләре бирү турында мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу журналында теркәлә (2 нче кушымта).

3.5. Ютазы муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасы гариза кергән көннән алып 30 көннән дә артмаган вакытта җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану турында килешү әзерли һәм бирә.

3.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.3 пункты таләпләренә туры килми торган документлар бирелгәндә, 2.2 пунктында каралган шартлар үтәлмәгәндә, шулай ук законнарда каралган башка очракларда, алар, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару сәбәпләрен аңлатып кире кайтарыла.

3.7. Гариза бирүчегә җибәрелгән килешү проектлары Ютазы муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасына гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән килешү проектларын алган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча имзаланырга һәм тапшырылырга тиеш.

3.8. Җир кишәрлеге бирелгән көннән соң биш ел узгач, гражданин мондый җир кишәрлеген билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдаланган очракта, объектны рөхсәт документлары нигезендә төзегән һәм төп эш урыны буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән белгечлек буенча эшләгән очракта, аңа җир кишәрлеге милеккә бушлай бирелергә мөмкин.

3.9. Граждан тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында билгеләнгән шартлар үтәлмәгән очракта, бирелгән җир кишәрлеге гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә алынырга тиеш.

Кушымта №1

Төп эш урыннары буенча Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль

районында эшләүче гражданнарга

җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга

бирү тәртибе турында Нигезләмәгә

Төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга бирү өчен җир кишәрлекләре реестры

| № т/б | Җир кишәрлеге адресы | Җир кишәрлеге мәйданы кв.м. | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Җирләр категориясе | Җир кишәрлеген файдалануның рөхсәт ителгән төре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Кушымта №2

Төп эш урыннары буенча Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль

районында эшләүче гражданнарга

җир кишәрлекләрен бушлай

файдалануга бирү тәртибе

турында Нигезләмәгә

Төп эш урыннары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында эшләүче гражданнарның җир кишәрлекләрен бушлай файдалануга бирү турында мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу журналы

| № т/б | Учетка кую өчен гариза бирү датасы | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Гариза бирүченең теркәлү урыны | Тапшырылган документлар исемлеге һәм реквизитлар | Җир кишәрлеген бирү турында билге (карар номеры һәм датасы) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |